**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

03 июнь 2024 № 796

**КАРАР**

**«Лаеш муниципаль районының юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү комиссиясе составын һәм Лаеш муниципаль районының юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 17 августындагы 2227 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (2023 елның 22 мартындагы 396 номерлы редакциядә үзгәреш)**

Кадрлар үзгәрү белән бәйле рәвештә карар бирәм**:**

1. «Юл хәрәкәте иминлеге буенча район комиссиясе составын һәм Лаеш муниципаль районының юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 17 августындагы 2227 номерлы карарына, 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.
2. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024елның 22 мартындагы 396 номерлы карарын үз көчен югалткан дип таныргa.
3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**

*Лаеш муниципаль районы*
*Башкарма комитетының*
*2024 елның __      __ номерлы карарына*
*1 кушымта*

## Юл хәрәкәте иминлеге буенча район комиссиясе составы

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | Нурмөхәммәтов Азат Әнәс улы | - | Район Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| 2. | Шитов Иван Петрович | - | Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (комиссия рәисе урынбасары); |
| 3 | Камалиев Ирек Камил улы | | Россия Эчке эшләр министрлыгының Лаеш районы буенча бүлеге башлыгы, (килешү буенча комиссия рәисе урынбасары); |
| 4. | Качалитова Галина Николаевна | - | Район Башкарма комитетының торак фондын төзүнең, ТКХ һәм исәпкә алуның баш белгече, комиссия секретаре; |
| Комиссия әгъзалары: | | | |
| 1. | Галеева Елена Николаевна | | Лаеш муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе |
| 2 | Шиһапов Марат Надир улы | - | Россия Эчке эшләр министрлыгының Лаеш районы буенча бүлеге ЮХИДИ бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| 3 | Зотин Ратмир Юсупович | | Район Башкарма комитетының торак фондын төзү, ТКХ һәм исәпкә алу бүлеге башлыгы; |
| 4. | Хөсәенова Лия Илдус кызы | - | «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы (килешү буенча); |
| 5. | Карсалов Алексей Петрович | - | Район Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы; |
| 4. | Хасаншина Лидия Рамил кызы | - | Район Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы вазифаларын башкаручы |
| 6. | Марьин Павел Юрьевич | - | Район Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы; |
| 7. | Фәйзуллин Марат Илфан улы | - | «Татавтодор» ААҖнең Шәһәр яны филиалы директоры (килешү буенча); |
| 8. | Коробова Елена Владимировна | | «Лаеш үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча); |
| 9. | Кузнецов Федор Сергеевич | - | Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының ГО һәм ЧС эшләре идарәсе  башлыгы  Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы  (килешү буенча); |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10. | Суханов<br>Денис Геннадьевич | - | «Кама ягы» («Камская новь») газетасының баш мөхәррире (килешү буенча); |
| 11 | Гәрәев Радик Әнвәр улы | | Дәүләт техник күзәтчелеге идарәсенең Лаеш районындагы бүлек начальнигы |
| 12. | «Юл хәрәкәте иминлеге» ДБУ вәкиле (килешү буенча); | | |
| 13. | Авыл җирлекләренең Башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) | | |

*Лаеш муниципаль районы*
*Башкарма комитетының*
*2024 елның __ __ номерлы карарына*
*2 кушымта*

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының юл хәрәкәте иминлеге комиссиясе турында нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы, ««2013 елга Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» республика максатчан программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 29 октябрендәге 911 номерлы карары (алга таба - комиссия) белән расланган, «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» республика максатчан программасына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 06 декабрендәге 961 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә эшләнгән.

1.2. Комиссия составына рәис (Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе), Рәис урынбасары, секретарь, комиссия әгъзалары керә.

1.3. Комиссиянең төп бурычлары булып юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән муниципаль органнар һәм иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлеген координацияләү, шулай ук юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтү буенча чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру тора.

1.4. Комиссиядә эшләргә барлык милек формасындагы предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешма вәкилләре җәлеп ителергә мөмкин (алга таба предприятиеләр).

1.5. Комиссия үз компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча карар кабул итә, алар предприятиеләр, вазифаи затлар һәм гражданнар өчен мәҗбүри. Предприятиеләр һәм вазифаи затлар ике атна эчендә комиссиягә комиссия карарын үтәү өчен кабул ителгән чаралар турында хәбәр итәргә тиеш.

II. Комиссиянең бурычлары

Юл хәрәкәте иминлеге буенча Комиссия:

2.1. Автомобиль транспорты предприятиеләре эшчәнлеген координацияләүне, автомобиль юллары төзүне һәм эксплуатацияләүне, транспорт хәрәкәте

куркынычсызлыгы мәсьәләләре буенча башка оешмаларны, авариялелекне киметү буенча эшне оештыруны тәэмин итә.

2.2. Юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтү буенча чаралар эшли һәм гамәлгә ашыра, автомобиль транспортының авариясез эшләве өчен шартлар тудыра.

2.3. Автомобиль транспорты хезмәткәрләре, транспорт чараларына хезмәт күрсәтүче башка хезмәткәрләр һәм транспорт чараларының шәхси хуҗалары арасында кирәкле профилактика эшен оештыра.

2.4. Транспорт, юл, проект һәм башка оешмалар һәм предприятиеләр тарафыннан юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтү буенча йөкләнгән бурычларның үтәлешен контрольдә тота, аларның эш тәҗрибәсен гомумиләштерә һәм тарата.

2.5. Предприятие эшчеләре һәм хезмәткәрләре, уку йортлары укучылары тарафыннан юл хәрәкәте кагыйдәләрен өйрәнүне оештыра.

2.6. Барлык массакүләм мәгълүмат чараларын кулланып юл хәрәкәте иминлеген пропагандалауны оештыра һәм гамәлгә ашыра.

2.7. Район территориясендә урнашкан автомобиль транспорты предприятиеләрендә хәрәкәт иминлеге өчен җәмәгать контроле комиссияләренә эшендә ярдәм күрсәтә.

III. Комиссиянең хокуклары

Юл хәрәкәте иминлеге буенча Комиссия:

3.1. Предприятиеләрне һәм оешмаларны юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлешендә тикшерә, комиссия утырышларында аларның җитәкчеләренең югарыда күрсәтелгән мәсьәләләр буенча кабул ителгән чаралар турында хәбәрләрен тыңлый.

3.2. Юл хәрәкәте иминлеге буенча кирәкле чаралар үткәрүдә җәмәгатьчелекне, шулай ук шәһәр һәм ведомство транспорты хезмәткәрләрен, транспорт чараларының шәхси хуҗаларын җәлеп итә.

3.3. Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча үзләренә йөкләнгән бурычларны канәгатьләнерлек үтәмәгән ведомство карамагындагы предприятиеләр җитәкчеләренә карата административ санкцияләр куллану турында тиешле органнарга тәкъдимнәр кертә. Күрсәтелгән органнар тәкъдимне карау нәтиҗәләре турында комиссиягә бер ай эчендә хәбәр итәргә тиеш.

IV. Комиссия эшен оештыру

4.1. Комиссияне рәис җитәкли, ул комиссия утырышларын даими чакыруны тәэмин итә, чираттагы утырышта каралырга тиешле мәсьәләләр даирәсен билгели. Утырышлар арасында комиссия әгъзаларына йөкләмәләр бирә һәм аларның үтәлешен тикшерә.

4.2. Комиссияне мәгълүмати-техник тәэмин итүне һәм документларны алып баруны комиссия секретаре оештыра. Протокол комиссия рәисе тарафыннан имзалана.

4.3. Комиссия утырышы аның составының яртысыннан ким булмаган өлеше

булганда хокуклы. Комиссия карарлары утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышлары белән кабул ителә һәм рәис тарафыннан имзалана.

4.4. Юл хәрәкәте иминлеге буенча комиссия составында эшче төркемнәр (машина йөртүчеләр арасында тәрбия эшләре, юл хәрәкәте кагыйдәләрен пропагандалау, юл шартларын яхшырту, машина йөртүчеләрне әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү, юл хәрәкәтен оештыру) һәм башкалар оештырылырга мөмкин.

«Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының «Юл хәрәкәте иминлеге буенча район комиссиясе составын һәм Лаеш муниципаль районы юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү комиссиясе составын раслау турында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 17 августындагы 2227 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының карарын килештерү кәгазе (2023 елның 22 мартындагы 396 номерлы редакциядә үзгәреш)

**Әзерләнде**:

Район Башкарма комитетының төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм торак фондын исәпкә алу бүлеге башлыгы

Г.Н. Качалитова

**Килештерелде:**

| | | |
|---|---|---|
| Район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары | ________________ | И.П. Шитов |
| Район Башкарма комитетының торак фондын төзү, ТКХ һәм исәпкә алу бүлеге башлыгы | ________________ | Р.Ю. Зотин |
| Район Башкарма комитетының юридик бүлеге баш белгече | _________________ | Е.П. Федорина |
| Район Башкарма комитетының оештыру-гомуми бүлеге башлыгы | _________________ | С.Н. Барышева |